# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлегенең Канаш торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2024 елның 24 ноябреннән №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Канаш торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елда Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлегенең Канаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, ташламага ия булучылардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Канаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Вальков